**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Пробуждение авылы торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**2025 елның 29 ноябре** **№ 2**

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Пробуждение авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Пробуждение авылы территориясендә 80 яшьтән өлкән кешеләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Пробуждение торак пунктында урам тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру):

-Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Пробуждение торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йөртүче хезмәтләре өчен түләү); Пробуждение торак пунктынын Татарстан урамынын юлын ремонтлау (таш белән капланган чокырлы ремонт, вак таш сатып алу, ташу, салу, грейдерлау, килешү буенча хезмәтләргә түләү), күпер ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләргә түләү);

-Пробуждение торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (улэн чабу, триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

-Торак пункт территориясен төзекләндерү (Пробуждение торак пункт территориясендә улэн чабу, (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү); триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьлар, чыгым материаллары сатып алу, килешу буенча хезмәтләр өчен түләү».

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р.Нуртдинов